# ГЫЙШЫК КОРБАННАРЫ

(Милли хикәя)

Сәгыйд бөек фамилияле, зур дәрәҗәле бер байның бердәнбер угылы иде. Гыйлем вә мәгърифәтле, тәрбияле гаилә эчендә дөньяга килмеш иде. Аны яшьтән үк тә яхшы тәрбияләгәннәр, укытканнар иде. Әхлаклы, тәрбияле, намуслы, вөҗданлы вә булдыклы бер зат иде. Наданнар гына түгел, бөекләр вә белемлеләр дә: «Кяшки[1], балаң Сәгыйд кебек булсачы!» — димәктәләр иде.

Гомуми халык тарафыннан бәхет вә сәгадәт саналган нәрсәләрдән мал вә дәүләт, гыйлем, тәүфикъ вә үткенлек кебиләрнең һәрбере Сәгыйдтә бар; чынлап ук та, Сәгыйд башкалар тарафыннан кызыгырлык вә макталырлык иде. Кайсы яктан караганда да сәгадәт вә муаффәкыять[2] бакчасында күренә иде.

Сәгыйд үзе дә бу яклардан бер кимчелек, бер җитешмәгәнлек тапмый, күңеле бу яктан тыныч иде. Әгәр болар белән генә сәгадәт вә бәхет камилләнә торган булса, Сәгыйд тә үз-үзене мәсгуд вә бәхтияр[3] саначак иде. Чынлаб ук та, мәсгуд, тыныч, кайгысыз, әләм вә кәдәрсез[4] яшәячәк иде.

Ләкин... ләкин... бу нәрсәләр Сәгыйд кашында чүп кенә күренәләр иде. Бу хасләтләрнең[5] вә бу кәмаләтнең[6] үзендә барлыгына карап, ул үзене мәсгуд вә бәхтияр саный алмый иде.

Бунлар Сәгыйдне шатландыра, кәефләндерә алмыйлар иде. Ул бунлардан бер тиенлек ләззәт, сафа, хозур тапмый иде. Аның күңеле бунлар белән хушланмый иде. Аның күңелендәге бөтен урынны үзенә алган икенче бер нәрсә бар иде.

Әгәр дөньяда бәхет вә сәгадәт була калса, Сәгыйд шул күңелендәге икенче бер нәрсә аркылы гына ул бәхет вә сәгадәткә ирешәчәк иде.

Ул икенче нәрсә дигәнем дә «гыйшык вә мәхәббәт»тер.

Сәгыйд байтактан бирле Галимә ханымның гыйшык вә мәхәббәтенә әсир иде. Бунлар Сәгыйдне шул дәрәҗә мәхкүм итмешләр иде ки, ул башка һичнәрсәгә әһәмият бирми, һичнәрсәне ярарлык дип белми иде.

Сәгыйднең күңелендәге гыйшык вә мәхәббәт, сөю уты, үзенең сөйгәне Галимә ханымга кавыша алмау куркусы бичара Сәгыйднең йөрәк маены ашый иде. Аның бөтен сәгатьләрене кайгы вә хәсрәттә, очы вә кырые булмаган хыял дәрьясында үткәрә, татлы йокыларыннан мәхрүм итә, ашарга-

---

[1]*Кяшки* — теләк белдергәндә кушып әйтелә торган сүз.
[2]*Сәгадәт вә муаффәкыять* — бәхет һәм уңыш.
[3]*Мәсгуд вә бәхтияр* — бәхетле, бәхет иясе.
[4]*Әләмвә кәдәрсез* — кайгы-хәсрәтсез.
[5]*Хасләтләрнең* — сыйфатларның.
[6]*Кәмаләтнең*— камиллекнең.

эчәргә вә башка ләззәт ала торган эшләргә ирек бирми иде. Һәрвакыт: «Аһ, Галимә! Аһ, сөеклем! Кайчан сиңа кавышып, бу өмидсезлектән котылырмын», — диярәк, йөрәгене угалый яки әллә ничә сәгатьләр бер тоташтан хыялда, вәһеми[1] кайгыда, башын бер якка салып, кулын яңагына таянып уздыра иде.

Сәгыйднең Галимәгә шул дәрәҗә мәхәббәте багланган, аңа гыйшкы шул дәрәҗәгә ирешкән иде ки, ул һәр заман Галимәне үз күзе алдында тотасы килә, аннан аз гына да аерылырга риза түгел иде.

Ләкин тормыш Сәгыйднең бу теләгенә бер дә ирек бирми иде. Бичара Сәгыйд күз алдыннан аерасы килмәгән Галимәне айда бер-ике мәртәбәдән артык күрә дә алмый иде. Күргән заманда да туйганчы сөйләшү мөмкин булмый, аз-маз сөйләшеп, тагы тизрәк аерылырга мәҗбүр булалар иде.

Өстәвенә, Сәгыйднең ата-анасы үзләренең байлык, дәрәҗә, фамилияләрене бер шәрәф[2] саныйлар, Сәгыйдне өйләндергәндә дә бу шәрәфкә кимчелек китерергә уйламыйлар, Сәгыйд исемнәрене ишеткәндә тәрбиясезлекләреннән җирәнә торган бай кызларыннан берене Сәгыйдкә юлдаш итмәк булалар иде. Кызы мәләк[3] кебек булса да, Галимәләр кебек түбән гаилә кызына риза булмаулары һәр сүзләреннән сизелә иде.

Галимәне күрә алмау хәсрәте белән газап чиккән Сәгыйднең аталарының бу сүзләре, бу фикерләре аның йөрәгене парә-парә ясый иде. Аталарының бу фикере, бу җаһиланә[4] гадәтләре Сәгыйднең бик эчене пошыра, кәефене кыра вә башына һич тә түзә алмаслык кайгы-хәсрәт җыела иде.

Аның кулларыннан тотып: «Җаным! Башымны киссәләр дә сездән башка берәүгә юлдаш булырга риза булу ихтималым юк. Миңа хәят булса, сезнең белән бергә булыр, сездән аерылсам, мин дөньяда тормам», — дип, мең кәррәләр[5] вәгъдә биргән, бөтен рухы аңа багланган, күңеле аның гыйшкына әсир булган Галимәсеннән аерылу түгел, хәтта аерылуны уйлау да Сәгыйд өчен үлемнән йөз кәррә яман иде.

Ул ике сүзнең берендә: «Йә, Галимә, йә үлем!» — дидер иде. Кая барса да, теле Галимә хакында сөйли, каләме Галимәне тәүсыйф кыла[6], күңеле Галимәне уйлый иде.

Хәзер аның хыялы башка һичнәрсә белән шөгыльләнми, гел Галимәгә кавышу, аның берлән бергә мәсгуданә[7] гомер итүне генә уйлата иде. Ул

---

[1]*Вәһеми* — хыялдагы уй.
[2]*Шәрәф* — дәрәҗә.
[3]*Мәләк* — фәрештә.
[4]*Җаһиланә* — надан кешечә.
[5]*Кәррәләр* — тапкырлар.
[6]*Тәүсыйф кыла* — сыйфатлый.
[7]*Мәсгуданә* — бәхетле рәвештә.

һичбер нәрсәдән ләззәт алмый, һичнәрсә аңа ләззәт, хозур, сафа, кәеф бирми, ялгыз Галимәне, аның алсу йөзләрене, йөзенең күркен арттыра торган җазибәле[1] озын керфекләрене, сөйләшкәндә адәмне хәйран итәрлек дәрәҗәдә сөйкемле кызгылт иреннәре, энҗе кеби тешләре берлән зиннәтләнгән агызыны, аллы-гөлле нурлы яңакларыны, кулыңа тотсаң җазибәсе бөтен тәнгә тәэсир итеп, үзеңне, дөньяңны оныттыра торган йомшак, нечкә кулларыны, ап-ак симез беләкләрене, нечкә билләрене, монтазам[2] төзелмеш сөяк вә әгъзаларыны, аның мәләк кебек кыланышларыны, бер ояла, бер мөхиббанә[3] рәвештә бөгелә-сыгыла сөйләшкән моңлы, ләтафәтле[4] сүзләрене, үз-үзене әллә нинди гали тәрбия күргән кызлардан артык дәрәҗәдә әдәпле, нәзакәтле, тәрбияле тота алуыны һәм башка кәмаләт вә фазыйләтләрене[5] уйлау вә шунларны үз күз алдына китереп кую гына Сәгыйдкә ләззәт вә кәеф бирә иде.

Ул инде башка нәрсәдә бу дәрәҗәдә ләззәт барына ышанудан үткән иде. Ләкин Галимәнең торышы хәленнән алган бу ләззәт озакка бармый иде. Ул бунлар белән бер уңгайдан Галимәне күптән бирле күрә алмавыны, аталары аңа риза булмауларыны уйлый да, әүвәлге ләззәтләрнең барысы кайгы-хәсрәт вә изтирабка[6] әйләнә иде: «Аһ, Галимә, кайчан сине күрермен?» — дип уф ора да башлый иде.

Аның хыялына Галимәне озак замангача күрә алмый йөрү, ахырдан барып та, әллә нинди манигълар[7] чыгып, Галимәдән мәхрүм вә фиракта калулар[8] килә дә, ул тагы кайгыга чума, башына әллә нинди өмидсезлек, муаффәкыятьсезлек, бәхетсезлекләр тула вә бөтен вөҗүдене[9] әләм, изтираб, ачы хәсрәт агуы каплый иде. Ул, үзене иң бәхетсезләрдән түбән төшерә торган бер бәхетсезлек — Галимәдән мәңге аерылуга үзенең очрау ихтималыны уйлап, үз-үзене өзгәләргә җитешә иде. Байлык, бөеклек, мәнсаб[10]-фәлән кебек чүп-чарлар булу белән, күңел тынычлыгы булмагач, сәгадәт буламыни? Рухани газап, мәгънәви изтираб[11] янында матди сәгадәтнең әсәре фаидәсе[12] беленәмени? — дип, үзенең халык тарафыннан сәгадәткә хисаплана торган нәрсәләрене ля шәйгә[13] саный иде.

---

[1]*Җазибәле* — үзенә тарту көче, сөйкемле.
[2]*Монтазам*— тәртипле, рәтле.
[3]*Мөхиббанә* — сөеп, яратып.
[4]*Ләтафәтле* — ягымлы.
[5]*Фазыйләтләрене* — өстенлекләрен.
[6]*Изтирабка* — тетрәнүгә, дулкынлануга.
[7]*Манигълар* — киртәләр.
[8]*Фиракта калулар* — аерылып калулар.
[9]*Бөтен вөҗүдене* — бөтен барлыгын.
[10]*Мәнсаб* — дәрәҗә.
[11]*Мәгънәви изтираб* — эчке дулкынлану.
[12]*Әсәре фаидәсе* — файдалы эзе, тәэсире.
[13]*Ля шәйгә* — юк нәрсәгә.

«Галимә берлән бергә яшәсәм, ач-ялангач булсам да, мин мәсгуд-бәхтиярмын[1], әгәр Галимәдән мәңге аерылсам, мин, алтын-гәүһәр эчендә йөзсәм дә, иң рәзилмен[2]», — сүзене һәр минут агызыннан чыгара иде.

Бөтен күңеле Галимәгә гыйшык-мәхәббәт белән тулган иде. Бөтен хәяты, тәгаллекаты[3] Галимәгә бағланган иде. Нә килсә шуннан киләчәк, бәхет вә сәгадәтле булса да, бәхетсез вә рәзаләтле булса да, Галимә аркылы булачак иде.

«Йә Галимә, йә үлем!» — аның даими тәсбихләреннән[4] иде.

**II**

Галимә ханым түбән, ярлы, гавами гаиләдән, нәсел-нәсәб, байлык, фамилия кебек ялган шәрифтән пакь бер кыз иде. Ата-аналары ярлы, надан булса да, үзләренең бер якынының дәлаләт вә ярдәме аркасында Галимә байтак кына укыган иде. Һәммә әгъзалары сәламәт, табигате саф, соң дәрәҗәдә матур, әдәпле, әхлаклы, галиҗәнаб, нәзакәтле, вә бик тә гыйффәтле вә намуслы иде. Гыйлем, тәрбия аркасында табигый булган кәмаләтене вә фәзаиле фитъриясене[5] тиешенчә тәрәккый иттергән[6], кайсы яктан караганда да ярыйсы иде. Кешенең күңелен җәлеп итәрлек, малга сәҗдә кылмаган, кеше мәхәббәт куярлык иде.

Ул үзе балигъ заманыннан бирле Сәгыйдне бик сөя: «Байлыгын әйтмим, әмма әхлак вә тәрбиясе шул Сәгыйд кебек бер адәмгә хатын булсам, үземне бәхтияр булыр идем», — диярәк Алладан тели иде.

Сәгыйдне күргән саен: «Аһ, егет! Табигать синең кебекләрне кяшки күбрәк үстерсәче!» — дип кала иде. Галимәнең күңелендә Сәгыйдкә никадәрле ихласлы мәхәббәт булса да, Сәгыйд кебекләрнең гомуми гадәтенә, аның ата-аналарына карап, Галимә Сәгыйдне бер дә өмид итми иде. Яратыр, безгә илтифат итәр дип күңеленә дә китерми иде. Шулай булса да, Сәгыйд Галимәнең күңелендә бик шәрәфле урын алмыш иде. Галимә Сәгыйд хакында тирән-тирән хыялларга бата иде.

Сәгыйднең һәр җәһәттән булган кәмаләтенә хәйран була, аңа каршы бөек бер ихтирам саклый иде. Галимәнең күңелендә әүвәлдән үк бу хисләр булганга, Сәгыйд Галимәгә үзенең мәхәббәтен белдереп, әгәр кабул итсә, бер күрешеп сөйләшәсе килгәнлегене бәян итеп мәктүб язгач, Галимәнең башы күккә тигән иде. Бу өнемме-төшемме диярәк, үз-үзене, дөньясын оныткан, үзенең Сәгыйд хакында күптән бирле саклап килгән хиссияте

---

[1] *Бәхтиярмын* — бәхетлемен.
[2] *Рәзил* — түбән, монда “бәхетсезмен” мәгънәсендә.
[3] *Тәгаллекаты* — бәйләнеше.
[4] *Тәсбихләреннән* — кабатлый торган сүзләреннән.
[5] *Фәзаиле фитъриясене* — тумыштан булган яхшы сыйфатларын.
[6] *Тәрәккый иттергән* — үстергән.

гашыйканәсене[1] бәян итеп, Сәгыйдкә бик тиз каршы җавап мәктүбе дә язган иде. Һәм беренче күрешүләрендүк Сәгыйднең илтифатын, чын мәхәббәтен аңлагач, Сәгыйднең муенына сарылып: «Җаным! Бар теләгем син иде, инде ирештем, мин сезнең бәндәңез, мин сезнең өчен корбан булам», — диярәк моңая-моңая, үзенең хиссиятене бәян итмеш иде.

Сәгыйд кебек бер зате гали[2] тарафыннан сөелүенә вә, аның бөтен иптәшләренә хилаф уларак, Галимәгә илтифат итүенә меңнәрчә тәшәккер укымыш[3], Сәгыйдкә әллә нинди хезмәтләр, фидаилекләр вәгъдә итмеш иде.

Кяшки Галимәнең бу көнге шатлык, өмид, мәсгудиятләрене, аның хиссиятене камилән[4] бәян итә алсамчы! Юк, мөмкин түгел. Булмый. Минем кебек гаҗизләр түгел, иң маһир каләмнәр дә Галимәнең ул көнге хиссиятене бәян итә алмаслар иде. Ул бичара Галимәнең сөйләүләре, көлүләре, кузгалыш вә йөрешләре — һәрбере аның шатлыгының чиксезлегеннән хәбәр бирәләр иде.

Ул шат, кәефле, күңеле әллә нинди өмидләр белән тулган иде. Бу көн анарга һәрнәрсә ямьле, шатлыклы иде. Дөнья нә? Тормыш нә? Кайгы нә? Ул барысыны да оныткан иде. Көләр йөзләреннән нурлар түгелә иде.

Шөбһәсез, Галимә туганнан бирле бондый шат, кәефле булган бер көнгә очрамагандыр.

Әгәр Галимәнең шул беренче күрешү көннәрендәге шатлыгы гомер буена дәвам итсә, белмим, Галимәнең хәле нә булыр иде?

Ләкин... ләкин...бу явыз фәләк[5]! Залим тәкъдир! Вафасыз[6] дөньяның бер шатлыгы мең, миллион төрле кайгылар белән чолгана шул! «Менә шатлык! Менә мәсгудият!» — дисәң, аның артыннан шундый ачы агулы бер хәл килеп чыга ки, син бу дөньяда әләм, кайгы вә газаптан башка нәрсә юк икән, дөньяның шатлыгы, өмиде бар да ялган имеш дип хөкем итәргә мәҗбүр буласың. Галимә ханым исә — ул бу көнге көн бу бәдиһи[7] фикерне хәтереннән чыгарган иде. Тирә-ягы мәсгудият, өмид белән тулган күренә иде.

Шулай булса да, фәләк үзенең әзәлдән[8] бирле адәм баласыны изеп, алдап килгән кануннарыны бер Галимә ханым хакында гына үзгәртмәде, Галимә ханымны кызганмады.

Дөнья дөньялыгыны итте, вафасызлыгыны Галимәгә дә күрсәтте.

Галимәнең ул шат, кәефле, көләч йөзле чаклары, күңеле әллә нинди

[1]*Хиссияте гашыйканәсене* — гыйшык тойгыларын.
[2]*Зате гали* —югары дәрәҗәле, аксөяк кеше.
[3]*Тәшәккер укымыш* — рәхмәт уку.
[4]*Камилән* — тулысынча.
[5]*Фәләк* — тәкъдир, язмыш.
[6]*Вафасыз* — тотрыклылыксыз.
[7]*Бәдиһи* — ап-ачык.
[8]*Әзәлдән* — мәңгелектән.

мәсгудият өмиде белән тулган заманнары озакка бармады. Ул әүвәлге төпсез-кырыйсыз шатлыклар урынына сансыз-хисапсыз ачы кайгылар, мәсгудият өмиде урынына өмидсезлекләр китерә башлады. Сәгать, көн вә төн үткән саен Галимәнең күңелендә Сәгыйдкә каршы гыйшык уты кызулана, ялкынлана, рухлары вә күңелләре һаман якыная бара иде. Ә җисемнәре бик ерак иде. Күрешү, сөйләшү айда бер-ике генә иде. Йөрәк ашкына, җан түзми, күрәсе килә, ләкин күрешү мөмкин түгел иде.

Мөстәбидانә[1] татар гадәте бунларны сөешүләрендә гаепли, араларында саф мәхәббәт, чын гыйшыктан башка һичнәрсә булмаса да, татар аңа фәхеш вә сәфаһәт[2] дип карый, бу мәгъсумнәрнең[3] күрешү вә сөйләшүләренә ирек бирми, зарыктыра, икесене ике урында саргайта иде.

Шул сәбәпле бичара Галимә кан-яшь аглый, башында бик каты кайгы-хәсрәт хөкем сөрә иде. Башы мәсгудият һәм ахыры да шулай булырга тиеш булган мәхәббәт Галимәне мәгънәви тәмугта, рухани газапта яшәтә иде.

Хосусән, Сәгыйднең ата-анасы белән Галимәнең ата-анасы арасында ялган, ләкин бик могтәбәр тотылган[4] шәрәф җәһәтеннән аерманың зурлыгы — Сәгыйднеке бай вә мәртәбәле, Галимәнеке ярлы вә түбән булуы — Галимәнең өмиденә каршы күренә, Галимәнең кайгысыны өсти иде. Галимә Сәгыйднең бу шәрәфене игътибар кылмавына күптән үк ышанган булса да, аталары риза булмас та, Сәгыйдтән мәңгегә аерылырмын дип бик курка иде. Моны уйлаган саен бер татар гадәтенә, бер тормышның тигезсезлегенә ләгънәт укый иде.

Исенә төшкән саен: «Илаһым! дәрәҗәсене тәкъдирдән гаҗиз булган бер нигъмәт биргән идең, инде аны тартып алырсың микән? Шул Сәгыйдемә кавыштырмый калдырырсың микән? Алай иткәнче, җанымны ал!» — дип кан-яшь түгәргә, үксеп-үксеп агларга керешә иде. Сәгыйднең үзене, кәмаләтене уйласа, ләззәт ала, аннан аерылуны һәм байтак көннән бирле аңа кавыша алмауны уйласа, йөрәгенә ут каба, хәзер уф орырга тотына иде. Соңга таба кайгы ягы күбрәк вакыт җиңә иде. Галимәдә уйлау вә хыял бер табигате сания[5] булып китмеш иде. Ул аз гына бушаса, хәзер уйга китә, хыялга бата иде. Сәгыйд белән күрешкән, сөйләшкән чаклар, киләчәктә күрешәчәкләрен, бер заман бөтенләй бергә яшәячәкләрен, мәсгуданә бер хәлдә гомер сөрәчәкләрен уйлый да, дәрте кузгалып, Сәгыйдтән килгән хатларны кат-кат укый башлый, Сәгыйднең рәсемене алып, битенә, йөзенә

---

[1]*Мөстәбиданә* — изүчеләрчә.
[2]*Сәфаһәт* — бозыклык.
[3]*Мәгъсумнәрнең* — гөнаһсызларның.
[4]*Могтәбәр тотылган* — зур бер нәрсә итеп каралган.
[5]*Табигате сания* — икенче табигать, гадәт.

куя-куя, аннан күзен алмый карап тора, там бер мәҗнүнчә[1] кыйлана иде.

Уйлый-уйлый үзенең бер ярлы гавам[2] баласы булуын, Сәгыйднең исә бай, мәртәбәле кеше баласы булуын вә тәрбиясез аталар боңа карап Галимәгә риза булмау ихтималларын, шулай итеп, Сәгыйдтән аерылу ачысыны татуларын хәтеренә китерә, хыялына гел кайгылы эшләр тезелә башлый иде. Шуннан соң бичараның төсләре бозыла, кәефләре китә, Сәгыйднең рәсеменә дә моңаеп кына карый башлый, йөзендә әллә нинди өмидсезлек әсәрләре беленә башлый, күзеннән энҗе кебек яшьләр алсу нурлы йөзенең буена юллар ясап, мөлдер-мөлдер тәгәри башлыйлар иде.

Галимәне там бер кызганычлык, аянычлык истиля кыла[3]. Бичара бик мәзлуманә[4], өмидсез бер сурәттә уйга китә иде. Галимәнең күп сәгатьләре шулай уйда, хыялда үтә иде. Аулак булдымы, тиз Галимә уйга чумган, күңеле әллә кайларны әйләнеп килә иде. Сәгыйдне әллә ниләр кыйлып уйлап бетерә иде.

## III

Җәйнең иң саф вә ләтыйф һавалы көне; шәһәрнең бакчасы төрле-төрле агачлар, гөлләр белән зиннәтләнгән, электрик яктысы бакчадагы бөтен караңгылыкны сөреп чыгарып, бакчаның һәр ноктасыны үз нурына гарык иткән[5], музыка да иң моңлы вә ләтафәтле көйләрне уйный, халыкны бер моңайта, бер кәефләндерә иде. Бакчада халык бик күп, барысы да ике ягы агачлы, комлы такыр юлдан акрын гына табигатьнең ләтафәтенә хәйран калып йөриләр иде.

Йөрүчеләр бар да шат, кәефле, һәрберсе үзенең никахлы яхуд булачак юлдашыны култыгына алып, ләззәт, хозур белән сөйләшеп күңел ачмакталар иде. Ялгыз бер ханым гына, тизрәк килсә ярар иде дигән төсле, бакчага да, халыкка да әһәмият бирмәенчә, үзенең хыялына әсир булып бер урындыкта хәзинанә[6] бер хәлдә утыра иде. Ул да — Галимә ханым иде.

Бу көн шул бакчада Сәгыйд белән күрешергә вәгъдә куйганга, аталарына мең төрле хәйләләр корып, бакчага килгән, Сәгыйдне көтеп утыра иде.

Галимә ханымның күзенә бакча да, халык та күренми, аның каршында бу сәгатьтә буларның бер тиенлек әһәмияте калмаган иде. Ул үзенең

---

[1]*Там бер мәҗнүнчә* — тәмам җенләнгән кеше шикелле.
[2]*Гавам* — гади халык.
[3]*Истиля кыла*— биләп ала.
[4]*Мәзлуманә* — кыерсытылган төстә.
[5]*Нурга гарык иткән* — нур белән күмгән.
[6]*Хәзинанә* — кайгылы, хәсрәтле сурәттә.

Сәгыйдене уйлый, аның хыялына бирелгән иде. Ялгызлык, сөйләшергә иптәшсезлек аны күңел галәменә, хыял дөньясына бирелдергән иде. Өстәвенә, музыка да үзенең моңлы көйләре белән Галимәнең күңелен бик нечкәләтә, аның иң тирән хисләрене уята иде; Галимәнең хыялга, уйга ныграк батуына ярдәм итә иде.

Галимәнең бакчага чыкканына байтак вакыт үтте. Вәгъдә куешкан сәгать тә артта калды. Сәгыйд әфәнде әле һаман юк, күренми дә. Баштарак гел Сәгыйд белән күрешү вә сөйләшү хакында уйласа да, Сәгыйд һаман да килмәгәч, аның килмәве хакында да уйларга тугры килә башлады. «Ник һаман килми икән? Ни булды икән? Озак заман аерылудан йөзләрем саргайды. Инде тагы күрми китәрем микән?» — сөальләре Галимәнең күңелене тырный, аның хиссиятене икенче якка авыштыра иде. Бәгъзан[1] алсу йөзләренә энҗе кебек күз яшьләре мөлдер-мөлдер коелгалый иде. Юк, һаман юк. Галимә мозтарибанә бер хәлдә[2] утыра иде.

Шул арада күзенә Сәгыйд белән ике арада хат йөртүче васита[3] күренде. Моны күрү Галимәгә җиңел булмады. Тәннәре эсселе-суыклы булып китте. Шулай булса да Галимә, үзене югалтмаенча,васитага бер аулак тарафны ишарә кылды.

Васита Сәгыйдтән килгән иде. Галимәгә сәлам, гафу үтенече хат китергән иде. Галимә васитадан: «Ни булды? Ник килми?» — дип сораша башласа да, васита: «Хаттан укып белерсең, байлар сизә башлар, миңа тизрәк кайтырга кирәк, — диде дә Галимәгә бер хат бирде. — Сәгыйд әфәнде сездән гафу үтенде, гаепләмәсен, бик көчле мәҗбүрият мине бүген вафасызлыкка мәҗбүр итте, диде», — дип, васита тизрәк өйгә таба юнәлде.

Үзенең күптән бирле күрми торган сөйгәненең йөзләрен күрү, аның кулларын кысып-кысып күрешү, кара-каршы утырып татлы сүзләр сөйләшү өмиде белән бакчага килгән Галимәгә ялгыз бер хат белән кайтып китү бик авыр иде. Бу Галимәнең башына бик зур инкыйлаб[4] ясаган иде. Аның башларына әллә нинди өмидсезлекләр биргән иде.

Галимә бакчага килгәндә, аяклары җиргә тими, башы кавышу өмиде белән тулы иде. Ә бакчадан кайтканда аның өчен бер атлавы да кыйммәт иде. Кавышам, күрешәм өмиде урынына: «Инде кайчангача тилмерермен, саргаермын икән?» — кайгылары урнашкан иде. Өмидсез, кәефсез иде. Бу мәктүбне укып, эчендәгесене аңлауны бер секунд кичектерергә риза булмаса да, нишләсен! Гомуми гадәт: урамда уку оят, шуның өчен өенә кайтканчы укымый сабыр итәргә мәҗбүр булмыш иде. Ул юлда бу мәктүбтә ни

[1]*Бәгъзан* — вакыт-вакыт.
[2]*Мозтарибанә бер хәлдә*— аптыраулы хәлдә.
[3]*Васита* — арадашлык итүче.
[4]*Инкыйлаб* — үзгәреш.

язылганыны белергә уйлап та бик азап чикте. «Ни бар икән? Әллә юкса аерылуны, билкөлли[1] ташлашуны муҗиб[2] булган берәр эш бар микән?» — дип аптырап килә иде. Кайтып өенә керде. Әле ярый, Галимәнең хәйләләре тугры, файдалы чыккан: Галимәнең кайда китүен сизмәгәннәр иде. Галимә тиз үк чишенде, лампыны кабызды да мәктүбне ашыга-ашыга укырга кереште.

Мәктүб ошбу рәвешчә язылган иде:

«Сөекле җаным!

Бәндәңезне гафу итеңез! Мин бу көн сезнең белән күрешү шәрәфеннән мәхрүм улдым. Бу көн фәләк бәни чиксез ачы бер мосыйбәтә мөбтәля итте[3]. Ләгънәт булсын аңа!

Сезнең белән күрешеп, ай буена җыелган хәсрәтләремне таратмак, хиссияте гашыйканәме бәян итмәк бу көн насыйбдыр өмиде белән, кичнең тизрәк килүене көтмәктә идем. Шул арада телеграмм килеп төште дә атам мине ирексезләп... гә җибәрде. Бу китеш, бу мәхрүмият минем өчен җан бирүдән дә кыенрак булса да, ни чара, җаным! Башка төшкәч түзәсең икән, мәҗбүрән киттем. Гафу ит, сөеклем!

Бу уйламаган мосыйбәт сезгә биззат юлыкып[4], кулларыңызы кысып, каршыңызда утырып, татлы сөйләшүдән мәхрүм иткәч, һич булмаса, әфкяремне[5] каләм илә бәян итим дип, сезгә мәктүб язмак булдым. Сезнең өчен әллә никадәрле кәгазьләр тутырсам, никадәрле сөйләсәм, ничек хәрәкәт итсәм дә күңелем канәгатьләнми, сезне уйлаган саен бер мәгънәви ләззәт хасил була. Җаным! Күңелемдә син, хыялымда син, фикеремдә дәхи син, хәят вә яшәвем дә синнән гыйбарәттер.

Байтак заманнан бирле сезне күрә алмау минем өчен иң бөек мосыйбәт булды. Сезне күрмәү мине һәлак итә, үтерә, җаным!

Нурлы йөзләреңезә карап хәйран улмак, кара алтындай сачләреңезне кулым илә тарамак, татлы сүзләреңезгә мөхатаб улмак[6] сәгадәтенә тизрәк ирешәсе килә. Сезне туйганчы күрмәк өчен гакде никахымызны[7] бераз әүвәл булдырырга телимен. Аталарыма буны әйтеп, мәрхәмәтләрене, шәфкатьләрене сорап аякларына егылачакмын. Мин хәзер башка һичнәрсәне уйлый алмыйм. Ялгыз сезне уйлыйм. Хыялым синең белән мәшгуль! Куәи фикриям сиңа мөнхәсыйр[8]! Аһ, гүзәлем!

---

[1]*Билкөлли* — бөтенләй.
[2]*Муҗиб* — сәбәп.
[3]*Мосыйбәтә мөбтәля итте* — кайгыга дучар итте.
[4]*Биззат юлыкып* — кара-каршы очрашып.
[5]*Әфкяремне* — фикерләремне.
[6]*Мөхатаб улмак* — тыңлау, тыңлаучы булу.
[7]*Гакде никахымызны* — никахлануыбызны.
[8]*Куәи фикриям сиңа мөнхәсыйр* — бөтен уй-фикер көчем сиңа төбәлгән.

Сезнең мәхәббәтеңез мине шул дәрәҗә горурлы, киберле[1] ясады ки, мин хәзер дөньяда сездән башка шаян мәхәббәт[2] бер затның булуына һич тә ышанмыйм. Сабыр итәргә мәҗалем[3] бетте. Түзәрлек хәлем калмады. Озакламыйм, аталарыма сезнең белән кавышу лөзүмене тиздән сөйлим. Беленез, җаным, бу көн бик якындыр. Беребез ахырдан аерылу уты белән януның актык сәгатьләре җитмештер. Инде озакламый кавышачакмыз, мәсгуданә бер тормыш корачакмыз. Бәхет вә сәгадәт, мәхәббәт эчендә икәүләп бергә йөзәчәкмез. Безгә башка сәгадәт кирәкми, сезнең белән кавышу – гайне сәгадәттер[4]. Безгә шул җитә...

Җаным! Шулай түгелме? Аһ, гүзәлем, ниләр уйлыйм? Ниләр хыяллыйм? Белсәң, дивана дияр идең. Саг булыңыз? «Аллаһы тизрәк кавыштырсын» догасилә мәктүбемне тәмам итәм.

Бакый[5] мәхәббәт... бәндәңез *Сәгыйд».*

Галимә, мәктүбне кулына алып укый башлагач, үз-үзене шул дәрәҗәдә югалтты ки, ничә кәррәләр укып чыкмаенча мәктүбтән бернәрсә дә аңлый алмады.

Аның бөтен вөҗүде әллә нинди бер каушау, изтираб[6] вә дәһшәт белән тулган иде. Күңелен, гакылын җыя алмый, билгеле бер ноктаны мөхакәмә итә[7] алмый, камил белемсез хәлдә иде. Нишләргә белми, үзенә ни булганын сизми, һаман мәктүбне кат-кат укый, аны үбеп йөзләренә куя иде. Шул рәвешле бераз заман үткәннән соң Галимә табигый хәленә кайта башлады. Үзене югалтмый, аңлап, мөхакәмә итеп укый башлады.

Бу мәктүб аның бакчадан кайтканда һәм теге васита мәктүбне биргән заманда хасил булган өмидсезлекләрене оныттырган, башындагы кайгы-хәсрәтләрене очырган иде. Ул мәктүбтән бик ләззәт ала, аны укыган саен шатлыгы, кәефе арта иде. Ул инде Сәгыйднең аталары риза булмавын яки башка бер-бер манигъләр сәбәпле Сәгыйдтән мәңге аерылу ихтималыны вакытлы гына булса да оныткан иде. Мәктүб аны там бер мәсгудият диңгезенә салган иде. Галимә мәктүбнең бер җөмләсене укый да әллә никадәрле тирән уйларга, төпсез хыялларга чума иде.

Тиздән никах һәм зөфаф[8] булачак, Сәгыйд белән Галимә кавышачак, бергә торачак; соң дәрәҗә мәхәббәт, мәсгудият белән гомер уздырачак, бер-беренә сарылып яшәячәк; балалар киләчәк, анлар «әти, әни» дип, әле

---

[1]*Киберле* — масаю, зурлык.
[2]*Шаян мәхәббәт* — мәхәббәтемә лаек.
[3]*Мәҗалем* — түземлегем.
[4]*Гайне сәгадәттер* — үзе бәхеттер.
[5]*Бакый* — мәңгелек.
[6]*Изтираб* – дулкынлану.
[7]*Мөхакәмә итә* — хөкем йөртә, уйлый .
[8]*Зөфаф* — яңа өйләнешкәннәрнең беренче киче.

Галимәгә, әле Сәгыйдкә йөгерешәчәк, уйнаячак; бунлар шуны карап дәхи ныграк бер-беренә мәхәббәт баглаячак, бар гомерләре там бер ләззәт вә мәсгудият эчендә үтәчәк, тагы әллә ниләр булачак. Бунлар барысы да Галимәнең күңеленә килә, күзе алдында берәм-берәм тезелеп торалар иде.

Галимә дөнья тормышының вә тәкъдирнең гел яхшы ягын гына уйлый иде. Бу дөньяның вафасызлыгын, фәләкнең залимлеген, тәкъдир мәсьәләсенең һәр ноктасы кайгыдан гыйбарәт идекене, бу өмидләр, бу хыяллар адәмне алдаткыч нәрсәләр генә идекене күңеленә дә кертми иде. Бу сәгатьләрдә, бу мәктүбне укыган заманда Галимәгә хасил булган өмид, мәсгудият бер татлы хыял дәрәҗәсеннән узмавын, бунлар артында әллә нинди кайгы-хәсрәт, әләм, изтыйраб яшеренеп торганлыгын хәтереннән билкөлли чыгарган иде.

Анларны үзе күреп, сынап үткәрсә дә, бу сәгатьтә анларга таба күңелене җибәрми иде. Вакыйган[1], уйларлык та түгел иде. Галимә дәрәҗәсендә гыйшык-мәхәббәт әсире булган бер йомшак күңелне түгел, ул Сәгыйднең хаты мәхәббәттән күп ләззәт алмаганнарны да эретерлек, үзләрене югалттырырлык иде. Галимәне исә бу хат хыял дөньясына, икенче күңел галәменә чыгарган, өмид диңгезенә салган иде. Барлык кайгы-хәсрәтне мувәкъкатән[2] чыгарып түктергән иде.

Татлы хыял! Өмид! Иштә[3] безем хәятымызны да шунлар гына саклыйдыр. Бунлар булмаса, адәм баласы күптән үк үз-үзене кабергә тутырыр иде. Хәятта әләмнән башка нәрсә юк. Дөньяда адәм кызыгырлык берни дә юк. Тик шул өмид кенә алдый. Шул өмид кенә аляме хәятны[4] аз күрсәтә, юкса ул әләмгә адәм түзәрлек түгелдер.

Галимә исә бу фәлсәфәне нәзарияттән түгел, гамәлән дә[5] белмеш, сынамыш исә дә, Сәгыйднең мәктүбе аны икенче хәлдә ясаган, гамәл вә тәҗрибәләрене хәтереннән чыгарткан иде.

Өмид, хыял аның гакыл вә тәҗрибәсенә галиб килгәнгә[6], ул Сәгыйднең: «Тиздән этиләремнән сезнең илә кавышырга, гакъде никах иттерергә сорыйм», — дигән сүзене сораган, беткән дип хөкем иткән кебек булган иде. «Аталары риза булмас» ягыны әүвәлдә һәр сәгатьтә уйлап, шуның өчен кайгырып торса да, бу хатның биргән өмидләре, татлы хыяллары хәзер аны оныттырган, теләгенә ирешмәү ягыны ул бу сәгатьтә хәтереннән чыгарган иде. Өмид, хыял Галимәне бик азга, бик билгеле вакыткача гына булса да

---

[1]*Вакыйган* — чыннан да.
[2]*Мувәкъкатән* — вакытлыча.
[3]*Иштә* — чынында.
[4]*Аляме хәятны* — тормыш газапларын.
[5]*Нәзарияттән түгел, гамәлән дә* — фикерләп кенә түгел, күреп-татып та.
[6]*Тәҗрибәсенә галиб килгәнгә* — хыял реаль хәлдән өстен булганга, аны каплап торганга.

җиңгән, тынычландырган иде.

**IV**

Галимә белән күрешкән, вәгъдәләшкән көннән башлап Сәгыйднең күңелендә ике төрле нәрсә, бер-беренә каршы ике хис сугыша иде. Берсе — Галимәгә булган чиксез гыйшкы; икенчесе — бу мәхәббәт вә гыйшыкны этиләренә әйтүдән оялуы иде. Үзенең мәхәббәте аталарыннан сорап тизрәк никах, зөфаф ясатырга ризалык алырга Сәгыйдне бик көчлидер иде. Икенче яктан, Сәгыйднең аталарына сөйләргә оялуы әүвәлге көчкә, әүвәлге теләүгә ирек бирми каршы тора иде.

Мәхәббәт сорарга көчли, ә оялу ирек бирми. Иштә Сәгыйднең куңелендәге сугыш! Сәгыйд Галимә хакында хыялга баткан саен бу сугыш башланып куя иде. Ләкин озын-озын уйланулары Галимә белән булачак мәсгуданә тормышны күз алдына китерүе заманында оялу хисе җиңелә, Сәгыйд тә: «Әлбәттә, калдырмыйм, бүген этиләргә әйтәм», — дип карар бирә иде. Шул фикерене әйтмәк булып ата-анасы янына кереп утыра иде. Ләкин ата-аналарының кибаранә[1] сүзләре вә үзләрене әллә кем санаулары Сәгыйднең күңелендәге оялу хиссене тагы кузгата, оялу ягы галиб булып, Сәгыйд әйтмәенчә калырга мәҗбүр була иде.

Бу сугыш, бу тартыш Сәгыйднең күңелендә күп заман хөкем сөргәннән соң, Сәгыйднең күңелендәге гыйшык вә мәхәббәт уты, кавышу дәрте аның күңеленә хуҗа булып, аннан үзенә каршы булган хисләрне куып чыгара башлады. Чөнки Сәгыйднең сабыр савыты тулмыш, артык түзәргә мәҗаль калмамыш иде. Кайгы, фирак аны измеш, тизрәк кавышу чарасына керешергә мәҗбүр итмеш иде.

Шулай итеп, Сәгыйднең күңелендәге сугышы «оялу» хисенең җиңелүе белән тәмам булмыш иде. Сәгыйд тә озакламады, ата-аналарына үзенең морады хакында сүз ачты. Әүвәлге сүзе каләм-мәктүб аркылы иде. Сәгыйд үзенең хәкиманә[2] фикерләрене, өйләнү ничек булырга тиешлегене, үзе кемне сөйгәнлегене мөфассаләнбәян итмеш[3], юк-бар шәрәфне игътибар кылмаенча, бу эшкә риза булуларыны бик үтенмеш иде.

Бу мәктүбне укыгач, ата-анасы, Сәгыйдне чакырып алып, шул хакта сүз кузгаттылар. Иң әүвәл Сәгыйдтән үз фикерене бәян кылдырдылар. Сәгыйд, бу форсатны ганимәт белеп[4], бу хакта ни фикере булса, аталарына барын түкте. Морадыны исбатлы сурәттә бәян итте. «Әгәр мине бала итсәңез, мәсгуд яшәсен дисәңез, бу морадны вөҗүдкә чыгарырга[5] каршы тормаңыз!»

---

[1]Кибаранә – олыланып.

[2]*Хәкиманә* — хәким кешеләргә лаек булган рәвештә; хәкимнәрчә .

[3]*Мөфассаләнбәян итмеш* — җентекләп сөйләп бирү.

[4]*Бу форсатны ганимәт белеп* — бу хәлне уңайлы санап.

[5]*Морадны вөҗүдкә чыгарырга*— теләкне тормышка ашырырга.

— диде.

Бу сүзләр Сәгыйднең аталарына бик гаҗәп тоела иде. Анлар үзләре Сәгыйднең бу фикергә килүенә бер дә сәбәп тапмыйлар, аптырыйлар иде. Анлар Сәгыйднең бу морадны гамәлгә куеп булуы ихтималлы эш түгел дип карыйлар иде. Сәгыйднең фикерене белгәч, анлар иң әүвәл башлап Сәгыйднең һәр яктан бәхетле, яхшы бер егет идекене, өстәвенә, дәүләт, мал, фамилия, мәнсаб та бик шәплекене бәян иттеләр. Бундый егеткә әллә нинди зур урыннардан хури кебек кызларны бирәчәк идекләрене сөйләп, Галимәне алырга риза түгеллекләрене әйттеләр. Сәгыйдне бу фикердән кайтару өчен үзләренчә вәгазь, нәсихәт тә иттеләр: «Булмас, юкны уйлама, өмидеңне өз», — диделәр.

Ләкин Сәгыйд өмид өзүдән, аннан башкага күңел салудан үткән иде. Бөтен дөнья көче җыелса да аерып ала алмаслык булып Галимәгә береккән иде. Аталарының вәгазь-нәсихәте, шелтәсе, бай кызы, хурилары-фәләне Сәгыйд кашында чүп кенә күренә иде. Ул бер кәррә сорау белән туктамады. Бер башлагач көн дә, көн дә аталарына шул хакта сүз ача, анларга ялына-ялвара, еглый, риза булуларыны үтенә иде. Мәхәббәт, гыйшык, сөю янында мал, дәүләт, мәнсаб, фамилия кебек нәрсәләр «һич» дәрәҗәсендә идекене аңлатырга тырышты. «Әгәр сез мине Галимәдән аерасыз икән, ул заманда миңа үпкәләмәңез! Мин Галимәдән башка яши алмыйм. Йә үлем! Йә Галимә!» — дип, үзенең актык дәрәҗәдәге нокталарынача сөйләмеш иде.

Юк, һаман да риза булмыйлар иде.

— Без үземез терек вакытта үз күз алдымызда, үз иркемез белән бердәнбер баламызны бер хәерчегә кияү ясау хурлыгына түзә алмыймыз. Бердәнбер углымызсың! Синнән башка угыл юк, кыз юк. Бар караганымыз син! Андый хәерче кызларыны йортымызга кертермен, бергә яшәрмен дип уйлама! Ул уеңнан кайт! Саташма! Гакылыңны җый, без һич бер заманда риза булу ихтималымыз юк, юкны өмид итмә! — диярәк, Сәгыйдне катгыян мәнгъ кылмышлар[1] иде.

Сәгыйд һаман да өмидене өзми: «Әллә кая бармаслар әле, бер вакыт риза булырлар. Инде яхшылык белән риза булмасалар, мин анларның ризагылына багланмаган, ризалыксыз ук алырмын да аерылып чыгарым», — дип уйлый иде. Үзе, һаман ялына-ялвара, каты-каты әйтеп карый иде. Икенче яктан васиталар аркылы да күндерергә тырыша иде. Ләкин эш бер дә уңгайга бармый иде. Аталары бер дә якын килмиләр: «Ул ярлыга катышыр хәлемез юк», — сүзләрене тәкрарлыйлар иде.

---

[1]*Катгыян мәнгъ кылмышлар* — катгый тыю, рөхсәт бирмәүләр.

**V**

Бу кайгылы эштән Галимә дә хәбәрсез түгел иде. Ата-аналарына ризалык сорап мәктүб язылганлыгыны, һәр көн, һәр вакыт анлардан сорамакта идекене бәян иткән мәктүбләр Сәгыйдтән Галимәгә һәр көн диярлек килә иде. Сәгыйднең мәктүбендә аталарының әле һаман риза булмауларыны язгач ук: «Җаным, анларның риза булмаулары гына безне аера алмас, без береккән инде. Риза булсалар булырлар, булмыйлар икән, башка чарасыны күрермен», — сүзләре дә язылган була иде. Мәктүбтә Галимәнең өмидене өздермәү, аны тәсәлли кылу[1] өчен байтак башка сүзләр дә язылгалый иде. Галимәдән башка яшәмәскә мең төрле вәгъдәләр, антлар яза иде.

Ләкин Галимәнең күңеленә бу хәбәрне ишетү бик уңгайсыз булды. Аны бик ачы кайгыларга, өмидсезлекләргә төшергән иде. Сәгыйднең тәсәллиләре, самими вәгъдәләре аның ашыккан күңелене баса алмый иде. Үзенең күңеленә яшьтән үк урнашкан: «Безгә андый бөекләр насыйб буламы соң!» — фикере Сәгыйднең әүвәлге мәктүбләре, күрешеп сөйләшүләре аркасында вакытлы гына күңеленнән чыккан булса да, риза булмау хәбәре ул фикерне тагы да кузгаткан иде. Бу хәбәр Галимәнең йөрәк маены ашый иде; аны бик каты әләм, фирак ачысына дучар итмеш иде. Сәгыйднең чынлап ук сөюенә ышанган булса да, йомшак күңелле, кызганучан егет аталарына каршы бара алмас, дип уйлый иде.

Галимәнең өмидләре, корган планнары берәм-берәм җимерелә, киләчәк мәсгуданә тормыш хыяллары оча иде, әүвәлге татлы хыяллары, кавышу фаразлары урынына тәмсез, ачы хыяллар, фирак кайгылары урнашмыш иде. Галимә әүвәлдә Сәгыйдне уйлаган саен бер төрле ләззәт, хозур таба иде. Кавышу көннәрене уйлый, Сәгыйд белән бергә булачак мәсгудиятле тормышыны хыял кыйла иде. Ә хәзер исә аның хыяллары, аның уйлары бөтенләй башкача иде. Ул үзенең киләчәк тормышы хакында уйлый башласа, аның хыялы гел кайгы-хәсрәт, кара көн, бәхетсезлек, Сәгыйдтән аерылуга вә изтирабка очрый иде. Күңелендәге ачы кайгы, агыр хәсрәт, каты газап түзә алмаслык бер дәрәҗәгә ирешә иде.

Бөтен дөнья аңа кайгының бер мөҗәссәм[2] мисалы кебек күренә иде. Дөньяда ләззәт, хозур, сафа, мәсгудият кебек нәрсәләрнең барлыгына, өмиднең вөҗүдкә чыгуына ышануы беткән иде. Кәефсез, өмидсез, дәртсез, шәүкъсыз[3] бер хәлгә килгән иде.

Галимәнең бу мәгънәви газабы көннән-көн катылана бара иде.

---

[1] *Тәсәлли кылу* — күңел күтәрү, юату.
[2] *Мөҗәссәм* — гәүдәләнгән, зур.
[3] *Шәүкъсыз* — кызыгусыз, теләксез.

Хосусән, Сәгыйднең соңгы көннәрдә: «Әле һаман риза булмыйлар, үзем дә өмид өзә башладым, ахрысы башка бер чара лязем[1]», — дигән хәбәре Галимәнең өмидене кискән, барлык хыялыны юкка чыгарган, буның агуы Галимәнең үзәгене өзгән иде. Бу мәгънәви газапның ачы агуы Галимәнең тәненә, матди хәятына[2] да тәэсир итмеш иде. Иң әүвәл Галимәдә йокы бетте. Ул һичбер йоклый алмый, төн буена әллә нинди төшләр, саташулар, куркыныч вакыйгалар белән азап чигә иде. Бара торгач аштан да, башка һичбер нәрсәдән дә ләззәт алмый башлады.

Мәгънәви газапның агуы, йокының юклыгы, ашауның юк дәрәҗәсендә булуы Галимәне һәр яктан бик начарлатмыш, хәлсез, куәтсез, зәгыйфь бер хәлдә калдырмыш иде. Ачы хәсрәт аның йөрәк маены ашый иде. Йокысызлык, ашсызлык матди хәятыны юк дәрәҗәсенә төшерә иде. Галимә шулай итеп түшәк әсире, авыру бәндәсе булып калмыш иде. Ул каты авырый башламыш, каны бик бозылмыш, урыныннан тора алмый ятарга мәҗбүр булмыш иде.

Бу үзәкне өзгеч хәбәрнең ишетелүе белән Сәгыйд бер докторны һәр көн Галимәне карап, дәва бирергә үз мәсарифе белән тәгаен кылмыш[3] иде. Доктор Галимәнең хәлене һәр көн Сәгыйдкә хәбәр итеп тора иде. Ләкин... аяныч, мең кәррә кызганыч ки, доктор никадәрле дәваласа да, Галимә бер дә алга бармый иде. Галимәнең авыруына сәбәп фирак[4] хәсрәте, кайгы агуы булганга, докторның матди дәвалары бер дә файда бирми иде. Галимә үзенең авыруында көннән-көн алга бара иде. Авыру көчәйгәннән-көчәя, Галимә бичара сызыла иде, кояштагы боз кебек эри, кибә-корый иде.

Аның төсе вә яме һаман үзгәрә, начарлана, кәмаләте берәм-берәм югала иде: нурлы алсу йөзләре зәгъфран кебек саргайган, тулып торган кызыл яңаклары эчкә баткан, күзләре чокырайган, кашлары салынган, бармаклары, беләкләре чыра кебек калган, кызыл иреннәре күгәргән, көләч-шат йөзләре ачы кайгы вә өмидсезлек әсәре белән тулган иде. Аның һәр сәгатьтә, һәр минутта: «Аһ, фәләк! Аһ, бәхет! Ашадың башымны!» — дип аһ оруы эчендәге кайгы, әләмнеңградысыннан[5] хәбәр бирә иде.

Галимә әгәр дә үзенең сөйгәне Сәгыйдне күрсә, сәламәтләнер кебек була иде. Авыру вакытында аны бигрәк күрәсе килә иде. Ләкин җаһиланә татар гадәте анларны күрешүдән манигъ кыла, анларның икесене ике урында канлы яшьләр түгәргә мәҗбүр итә иде. Никадәрле тырышса да, үзенең сөйгәне Сәгыйднең кулыннан тотып, кара-каршы сөйләшмәк Галимәгә

---

[1] *Лязем* — кирәк, тиеш.

[2] *Матди хәятына* — бу урында сәламәтлегенә мәгънәсендә.

[3] *Үз мәсарифе белән тәгаен кылмыш* — чыгымнарны үз өстенә алган.

[4] *Фирак* – аерылышу.

[5] *Градысыннан* — градусыннан, температурадан.

насыйб булмый иде. Бусы Галимә өчен, егылганны түбәләү[1] дигәндәй, авыру өстенә авыру була иде. Галимәнең җаныны бигрәк тә өзә, аны тагы ныграк зәгыйфьләтә иде. Галимә көннән-көн артка китә, тыны, сулышы кысыла башлый. Доктор да бер дә өмидле нәрсә сөйләми: «Белмим, берни дә әйтә алмыйм», — дип кенә куя иде.

Вафасыз дөнья дөньялыгыны итте.

Сәгыйдкә катнашканына ике ел тулып өченчегә киткәндә, май аенда Галимә ханым гыйшкына корбан булды. Аның ярлылыгы, аның сөйгәненә кавышудан өмид өзүе: «Алайса мин бу дөньяда тора алмыйм», — диярәк, мәнбәгы алям[2] булган бу вафасыз дөньяны ташлап, караңгы кабергә керергә мәҗбүр итте. Галимә ханым вафат булды.

Таң алдында таш йөрәкләрне дә эретә торган: «Галимә үлде, аһ, балам әрәм булды!» — дигән йөрәк өзгеч тавыш, җәрәхәтле аваз асманга[3] ашмакта иде.

Хатыннар җыелды. Еглыйлар, үксиләр: «Аһ, бичара, бигрәк яшь көйгә әрәм булды, арада бер кыз иде, ичмаса кияүгә дә бара алмады», — дип Галимәне кызганалар, аналарыны тәсәлли хатир итмәк[4] булалар иде. Ата-анасы исә — анлар инде үзләрене билкөлли югалтканнар, еглый-еглый шешенеп беткәннәр иде.

Бөтен йортта аһ-ваһ, еглау, үксү, шау-шу, аптырау, күз яше, моңлы-моңлы зарыгу, зарлану тулган иде. Бер кечкенә мәхшәр иде. Һәркемдә кызганырлык бер күренеш иде. Аяныч! Кызганыч! Күздән кан агызгыч бер хәл иде.

Үлүен генә үл инде! Сине озакламыйлар, чокыйлар да сине җиргә тыгалар. Бу нәүбәт Галимәгә дә килде. Галимә үлгәч үк каберене казыганнар, башка кирәк-яракны да хәзерләгәннәр иде. Өйләгә таба эшне бетереп, бер көтү халык җеназаны зиратка да китермешләр, жәлләми-кызганмый Галимәне гүргә салып, таптап-таптап күмгәннәр дә иде. Җеназа чыкканда карап калган хатын-кызның аһ-зары таш күңелне дә йомшата, аглата иде.

Шулай итеп, бичара Галимә, үзенең сөйгәненә юлыкуда өмидсезлек сәбәпле, дөньяга вә хәяткә видаг итте[5]. Сәгыйдсез — киң, якты дөнья тар, караңгы кабердән яман күренде. Гыйшык-мәхәббәт юлында үзене корбан итте. Фәләк, тәкъдир майның егерме бишенче көнендә рухлары, күңелләре тәмамән береккән ике яр гашыйкның араларыны золмән[6] өзеп, берсене гүргә

---

[1]*Егылганны түбәләү* – бер бәлагә дучар булган кешегә яңадан-яңа бәла өстәлүгә карата.
[2]*Мәнбәгы алям* — газаплар чыганагы.
[3]*Асманга* — күккә.
[4]*Тәсәлли хатир итмәк* — юатырга, күңелен табарга тырышу.
[5]*Видаг итте*— хушлашты.
[6]*Золмән* — золым белән.

тыкты, икенчесене дә кан-яшь аглатып гүргә керерлек кенә бер хәлдә ясады. Галимәне бер нәрсә дә котылдыра алмады. Ул аглый-аглый гүргә керде.

**VI**

Галимәнең Сәгыйд хәсрәте өчен бу кадәрле авыруы, газаплануы Сәгыйднең үзе авырудан, үзе газап чигүдән дә яманрак тоела иде. Галимәнең бу авыруына Сәгыйд сәбәп булганга, берәүнең тәрк хәятына[1] сәбәп булмасам ярар иде дип, бер яктан, курка, йөрәге яна, икенче яктан, Галимәдән мәңгелек аерылу ачысы аның үзәгене тәмам өзә иде. Сәгыйднең бер кайгысы мең булмыш, бөтен башы өмидсезлек, муаффәкыятьсезлек белән тулмыш, там бер мәгънәви тәмуг эчендә калмыш иде.

Майның егерме бишенче көнендә Сәгыйд үзләренең бакчасында: «Ни булды икән? Галимә ни хәлдә ята икән? Ник бу васита тизрәк кайтмый икән?» — дип, үз алдына сөйләнеп акрын гына йөри иде. Шул арада бакча ишеге ачылып китте. Караса: ашыга-ашыга васитаның килгәнене күрде. Васита Галимәләргә хәбәр алырга китмеш иде. Сәгыйд, күрүгә, васитага таба атылды. «Ни бар? Ни хәлдә?» — дип кызу-кызу сораша башлады. Васита бик еглый, сүзене сөйли алмый иде. Ничек җитте алай итеп: «Галимә ханым вафат!» — дигән агулы сүзне әйтә алды. «Аһ, аяныч! Галимә ханым вафат!» — никадәрле агулы, никадәрле җәрәхәтле, ишетергә сөйкемсез ачы сүздер!

Васитаның агызыннан чыгып, һава бу сүзне Сәгыйднең колагына ирештергәндүк, бу сүзнең агуы, зәһәре Сәгыйднең иң эчке нокталарына кадәрле йөгерде. Сәгыйд: «Ни дисең? Галимә ханым вафатмы? Аһ, җаным! Кашки бу сүзне ишеткәнче үк үзем үлсәм, никадәрле бәхтияр булыр идем», — ди дә: «Аһ, җаным! Аһ, сөеклем Галимә!» — дип бөгелеп төшә, бөтен куәтеннән яза. Җиргә егылып агларга керешә! «Гафу ит, җаным! Золым иттем, сине харап иттем, вакытсыз сиңа әҗәл китердем! Һич булмаса актык сулышында кулларыннан тотып бәхиллек тә ала алмадым. Җаным! Син үлдең, котылдың! Мин нишлим?» — дип, сабыйлар кебек сулыгып еглый, күз яшене түгә.

Бакчада кеше юк, булса да, Сәгыйд күзенә күренми. Ул һушсыз, тәмам һушсыз, ни эшләгәнене дә белмәенче еглый иде. Күзләре, битләре шешенгәнче еглады. Ул үзенең бу еглавы, бу кадәрле күз яше түгүе белән күңелендәге кайгыларыны жуып төшермәк, агызмак була иде. Ләкин еглаган саен йөрәге ашкына бара иде. Еглау кайгысыны баса алмый иде. Ахырда үз-үзене тотып: «Еглап файда булмас, ичмаса женазасына барырга кирәк», — дип, жуынырга кереп китте.

Ашыга-ашыга жуынып, киенеп чыкты да Галимәләр тарафына юнәлде.

---

[1] *Тәрк хәятына* — дөньяны ташлавына.

Сәгыйд барганда Галимә ханымның җеназасыны капкаларыннан алып чыгып киләләр иде. Бу җеназаны күрү Сәгыйд өчен җаныннан аерылудан да читенрәк булса да, Сәгыйднең йөрәк уты ашкынып, тәмам һушсызланырга якынлашса да, Сәгыйднең бер дусты тиешле тәдбирләр[1] белән Сәгыйдне тыя алган иде. Сәгыйднең күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр бер-бер артлы коелса да, һаман да уйны билкөлли югалтмаган иде. Исенә төшеп тыела алмый башласа, йә артка кала, йә читкә чыга иде. Галимәне кабергә салганда да, аны караңгы кабергә салып, ашыга-ашыга күмгәндә дә, үзенең сабыр итә алмавыны белеп, Сәгыйд әфәнде кабер тирәсенә килмәгән иде. Үзенең сере сыйган дусты белән сөйләшкән булып, тугрысыда, сулыгып, еглап: «Аһ, җаным! Мине калдырдың бит!» — дип, читтә кан-яшь түгеп торырга мәҗбүр булмыш иде.

Сәгыйд үзе кабер тирәсенә килмәк булып ашкынып караса да, дусты аны җибәрми иде. Чөнки Сәгыйднең фирак уты, аның гыйшык вә мәхәббәт хисе бу көн сабыр савытыны җырткан, оялуга да, халыкның көлүенә дә галәбә иткән[2] иде. Ул үз-үзене белми: «Аһ, сөеклем!»нән башка берни сөйли алмый иде. Халык, гадәт, оят — бу көн бунларның барысы да Сәгыйд кашында чүп кенә иде.

Күмеп беткәч, башка халык белән бергә Сәгыйд әфәнде үзенең юлдашыны да җибәрмеш, үзе кабер янында ялгыз калмыш иде. Галимәнең кабере янына утырып бер аглый, бер бик тирән уйга чума иде.

Кабер янында байтак заман аглады. Үзенең фирак хәсрәтенең кызу янган утыны сүндерергә тырышты, ләкин... бу сүнәме? Һәйһат[3]... үзең бетми, рухың сүнми торып аның сүнү ихтималы юк инде. Бу еглаулар, бу канлы яшьләр йөрәк ялкыныны сүндерүдә файда бирмәячәгене Сәгыйд баштарак хәтерләмәсә дә, соңга таба аңлаган иде. Кабер янында аглаган саен йөрәге һаман ашкына, кайгы ачысы үзәгенә үтә барганга, бунда аглаудан файда юк дип, өенә таба юнәлмеш иде.

Сәгыйд бүген там бер мәҗнүн булмыш, фирак уты аның гаклыны яндырмыш иде. Атлаган саен Галимәнең каберенә әйләнеп карый, үз алдына мәҗнүнанә бер хәлдә ошбу сүзләрне сөйләнә иде:

— Сөеклем Галимә! Бәндәңезне гафу идеңез! Мин сезне харап иттем. Сез минем атамның бөеклек, байлык кебек ялган шәрәфенең мәзлумияте[4] астында изелдеңез, байлык, сәрвәт[5] мине сездән аерды. Икемез берлектә

---

[1]*Тәдбирләр* — чаралар.

[2]*Галәбә иткән* — җиңгән, өстенлек алган.

[3]*Һәйһат* — үкенеч белдерүче сүз(кире кайтаруы мөмкин булмаган бер нәрсә өчен өзәлəнгәндә әйтелә торган ымлык).

[4]*Мәзлумияте* — җәберләве.

[5]*Сәрвәт* — дәүләт, байлык.

мәсгуданә бер хәлдә яшәүдән тыйды. Ләгънәт бу байлыкка, бу сәрвәткә! Ләгънәт бу тигезсезлеккә! Җаным! Син үлдең, котылдың! Мин ни эшлим? Актык антым, соң вәгъдәм: мин яшәсәм, сезнең мәхәббәтеңез, сезнең хыялыңыз белән яшәячәкмен! Башка берәүгә юлдаш булу миңа вөҗданән хәрамдыр. Ләкин мин яшәмәм! Мин тора алмам. Синсез тереклек миңа кирәкми. Ахрысы мин дә озакламый сезнең арттан гүргә китәрмен. Хәзергә әлвидаг, җаным! Әлвидаг[1]!

Бу вакытларда Сәгыйдтә хыял, мәгънәви газап,әләм, изтирабтан башка бер нәрсә калмаган иде. Хәл дә юк, куәт тә юк, гакыл вә фикер дә йөрми, аяклары атламый иде. Ничек җитте алай бүлмәсенә кайтып егылды. Ул көн ашамады, эчмәде, чакырсалар да бармады. Ата-анасы, байлык, мәртәбә, бөеклекләре Сәгыйдкә дошман күренәләр, Сәгыйднең Галимәсене золмән кабергә тыгучы күренәләр иде. Ул бу көн һич нәрсәдән риза түгел, һәр нәрсә аңа залим, мөстәбид[2] күренә иде. Дөнья, тормыш, татар гадәте, фәләк, тәкъдир, бәхет кебек гомуми нәрсәләргә бер-бере артлы бәйләнә, анларны сүгә, үзенең бу хәлгә төшүендә анларны гаепли иде. Бүлмәсе бикле, лампы янып утыра, Сәгыйд тә әле килеп утыра, әле торып китеп, йөри башлый. Хасиле, там бер наразыйлык[3], чыдамсызлык эчендә иде. Аның хыялы бу көн бигрәк тирән, бигрәк төпсез иде.

Ул үзенең белә башлаганнан бирле очраган вөкугате хәятиясене[4] уйлый, үткән эшләрене берәм-берәм тикшерә, ни күргән, һәммәсене исенә төшерә иде. Иң әүвәл күрешкән заманында Галимәнең бер оялыбрак, бер мөхиббанә[5] сурәттә моңаюлары, Сәгыйдтән күзене алмаенча, озын керфекләре аркылы җазибәле[6] карашлары: «Җаным! Сине күрмәсәм, йөрәгемә түзә алмыйм», — дип мөхиббанә Сәгыйднең муенына сарылулары, шуннан соң бер-беренең кочагына атылышып үбешүләре, Галимәнең бөек хезмәтләр, чиксез фидаилекләр, вәгъдә һәм хиссияте гашыйканәсене бәян илә тулган татлы сүзләре, бунлар артыннан аның авырып, саргаеп ятулары, Сәгыйднең хәсрәте сәбәпле вафат булып, тар, караңгы, салкын, каты кабергә керүләре, халык аны бер дә кызганмаенча таптап күмүләре, кабердә ялгыз калуы — һәммәсе дә Сәгыйднең күңеленә берәм-берәм тулалар иде. Хыял бунларны Сәгыйднең күз алдына китереп тезә, вәһем[7] исә анларны мөҗәссәм ясап күрсәтә иде. Бу хыял җебенә тезелгән вөкугатнең әүвәлгеләре Сәгыйдкә бераз ләззәт бирсә дә, Галимәнең авыруы, үлүе тирәләренә килсә, Сәгыйдне

[1]*Әлвидаг* — сау бул, хуш!
[2]*Мөстәбид* — изүче, үзе теләгәнчә эш йөртүче.
[3]*Хасиле, там бер наразыйлык* — кыскасы, тулы ризасызлык.
[4]*Вөкугате хәятиясене*— тормыш вакыйгаларын.
[5]*Мөхиббанә* — сөеп, яратып.
[6]*Җазибәле* – сөйкемле.
[7]*Вәһем* — хыялдагы уй.

бик изә, вөждан вә рухыны газаплый, сабыр итә алмаслык дәрәҗәгә китерә иде. Бу соңгы нокталарда Сәгыйд утырып түзә алмый, аяк үрә йөри башлый, йөрәгенең утыннан: «Уф, аһ!» — сүзләре белән бергә төтеннәр чыга иде. Бу газап, бу әләмне кемгә сылтарга белми, ничек котылырга чара тапмый иде. Тагы әллә нинди хыялга бата, Галимәнең кабергә керүе исенә төшә дә тагы бер кәррә уф ора... Үз алдына нидер сөйләнә башлый иде. Караган кеше аны шөбһәсез дивана зан итәчәк[1] иде. Аның бөтен йөзе өмидсезлек әсәре белән тулган иде.

Фәләкнең иза-җәфасыннан, тормышның тигезсез, әләм вә кәдәрле[2] булуыннан, дөньяның вафасыз, алдаучылыгыннан, тәкъдирнең бер-бер артлы тезгән кайгы-хәсрәт вә өмидсезлегеннән, бәхетнең соң дәрәҗә каралыгыннан бик мәзлумият[3] катыш ачу белән зарлана иде. Бунлардан башка һич нәрсә күрү мөмкин түгелдер инде! Дөньяда рәхәт, сәгадәт, хозур, сафа, ләззәт — барысы да исеме бар, мөсәммасы юк[4] нәрсәләр, имеш. Дөнья, тормыш — һәммәсе алдагыч, вафасыз, ялганчы, имеш, тормыйм бу дөньяда! Ташлыйм бу тереклекемне! «Галимә китте, аның артыннан барырга вөжданән мин дә мәҗбүрмен. Мадам ки[5] дөнья тереклеге миңа кызыгырлык бер нәрсә дә бирми, һаман алдый, золым итә. Ул тереклек, андыйфайдасыз хәят миңа ник кирәк? — ди дә, стенадагы револьверыны кулына алып, аны кора да күкрәгенә төзәп атмакчы була. — Атылам, атылам, тормыйм бу дөньяда!» — дия иде.

Тагы туктый, револьверны өстәлгә куеп, лампыны бераз караңгылата да тагы хыялга бата... Үзенең атылып үлүене, револьвер тавышына халык җыелуыны, аны кабергә тыгып ялгыз калдыруларыны, «Ник үлде? Ни өчен атылды?» — дип тәшвиш вә сөаль булуыны уйлый иде. Бу тәшвишкә, бу сөальгә җавап язмак булып, өстәлгә килеп каләм, кәгазь ала да: «Языйммы, юкмы?» — дип уйлый башлый. Күңеле аңа: «Яз! Яз!» — ди. Сәгыйд тә яза башлый. Озак вакыт яза алмый, кулы бармый, аннан-буннан сызгалый да, кәгазьне алып кесәсенә сала, каләмене каядыр ыргытып бәрә. Сәгыйд хәзер үз-үзене югалткан, аңа хыял баш булган иде. Ул үз-үзене хыялдан котылдыра алмый иде. Аның күңеле, хыялы актык сәерем[6] диярәк, бөтен дөньяны әйләнде; үзенең актык сәгатьләренәчә булган вөкугатене тагы бер кәррә кичерде. Галимәнең Сәгыйд өчен кабергә керү ноктасына килеп җиткәч,

---

[1]*Дивана зан итәчәк*— юләр дип уйлаячак.
[2]*Әләм вә кәдәрле* — кайгы-хәсрәтле.
[3]*Мәзлумият* – рәнҗетелгәнлек.
[4]*Мөсәммасы юк* — җисеме (үзе) юк.
[5]*Мадам ки* — чөнки.

[6]*Сәерем* – йөрүем.

Сәгыйднең сабыр итәргә мәҗале калмады[1]. Сикереп торды да: «Ләгънәт сиңа, дөнья! Ләгънәт сиңа, тормыш!» — диярәк, револьверны кулына алып, берничә кәррә тоташтан күкрәгенә атып та җибәрде. Пуләләр бер уңгайдан берничәсе Сәгыйднең йөрәгенә барып кадалды. Сәгыйд тә: «Аһ, җаным! Аһ, йөрәгем!» — дип, дөбердәп төшеп идәнгә егылган иде.

Револьвер тавышына йокыдагы ата-анасы вә башкалар уяндылар: «Ни бар? Кемне аттылар?» — дип, Сәгыйднең бүлмәсенә йөгерештеләр. Бүлмә бикле иде. «Сәгыйд! Ач ишегеңне!» — диләр. Җавап юк. Тиз үк ишекне ватып кереп, лампыны яндырдылар. Ни күзең белән күрәсең? Сәгыйд идәнгә бөкләнеп төшкән. Агыз да юк, тел дә юк. Инде актык сулышыны суламакта иде. Күрү белән ата-анасы һәр икесе дә: «Аһ, балам! Аһ, Сәгыйдем!» — диделәр дә һушсыз булып егылдылар.

Халык җыелды. Озакламый политсә[2] дә килде. «Ни бар да, ни бар?» Шау-шу купты. Политсә һич кемне якын җибәрми, һич нәрсәгә кагылдырмый иде. Үзе чишендерә, кесәләрене актара иде. Кесәдән башка һич нәрсә чыкмады; ялгыз бер кәгазь чыкты. Кәгазьне укыдылар. Анда шул сүзләр язылган иде:

«Хөрмәтле атам һәм анам! Сезгә угылыңыз Сәгыйдтән актык сүз: үзеңезнең байлык вә бөеклегеңезне бер шәрәф санап, мине җан сөйгәнемнән аердыңыз... Минем сөйгәнемне, аннан башка тереклекемне үземә хәрам кылмыш ярымны залиманә кабергә тыктыңыз... Инде мин үзем дә сөйгәнем артыннан китәргә вөҗданән вә намусән мәҗбүрмен. Мин сезгә баштук: «Йә Галимә! Йә үлем!» — димеш идем. Сез Галимәгә риза булмадыңыз, алайса инде минем үлүемә дә үпкәләмәңез! Мине кичереңез! Гафу итеңез! Мин атылдым, чөнки сөйгәнем үлде. Дөнья сездән гыйбрәт алсын!»

---

[1] *Мәҗале калмады* – түземлеге калмады.
[2] *Политсә* – полиция.